ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм “Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында” Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында” 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), “, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләр” сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында” 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә “, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 өлешнең 6 пунктында “, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне” сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.




Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 8 октябре
№ 72-ТРЗ